КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 декабрь г.Казань № 1182

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 27 май, 432 нче карары белән расланган Сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә аларның инфраструктурасын үстерүгә мөлкәт арендасыннан алып бетерелмәгән керемнәр күләмендә заемнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен 2020 елда «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә аларның инфраструкту-расын үстерүгә мөлкәт арендасыннан алып бетерелмәгән керемнәр күләмендә заемнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен 2020 елда «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 27 май, 432 нче карары белән расланган Сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә аларның инфраструктурасын үстерүгә мөлкәт арендасыннан алып бетерелмәгән керемнәр

күләмендә заемнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен 2020 елда «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарның юнәлеше булып сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарәче компанияләренә күчемсез мөлкәт объектларын арендалаудан алынмаган керемнәр күләмендә аларның инфраструктурасын үстерүгә заемнар бирү тора.»;

2 пунктның икенче абзацында «вәкаләтле орган» сүзләрен «бюджет акчаларын баш бүлүче» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «вәкаләтле орган» сүзләрен «бюджет акчаларын баш бүлүче» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта:

өченче абзацта «һәм вакыты узган башка» сүзләреннән соң «(җайга салынмаган)» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки оешманың баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмау;

бу Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алырга тиеш түгел.»;

5 пунктта:

беренче абзацта «вәкаләтле органга» сүзләрен «бюджет акчаларын баш бүлүчегә» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «вәкаләтле орган» сүзләрен «бюджет акчаларын баш бүлүче» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче абзацта «вәкаләтле орган» сүзләрен «бюджет акчаларын баш бүлүче» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «вәкаләтле орган» сүзләрен «бюджет акчаларын баш бүлүче» сүзләренә алмаштырырга, «Вәкаләтле орган» сүзләрен «Бюджет акчаларын баш бүлүче» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фонд тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү;»;

8 пунктта «Вәкаләтле орган» сүзләрен «Бюджет акчаларын баш бүлүче» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Субсидия бирү бюджет акчаларын баш бүлүче белән Фонд арасында төзелгән Килешү нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәренә исәпләнә биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләре, аны Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү шартлары һәм тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәләренең мәгънәләре;

субсидияне күчерү вакытлары һәм тәртибе;

Фонд тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында һәм финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында, шулай ук өстәмә хисаплылык (кирәк булганда) бирү сроклары һәм формалары;

субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылганда субсидияне кире кайтару очраклары;

штраф санкцияләрен куллану очраклары һәм тәртибе;

алынган субсидия исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны (югары технологияле чит ил җиһазы, чималы һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) тыю;

заем акчаларыннан максатчан файдалануны тикшереп торуны гамәлгә ашыруда Фондның бурычы;

Килешү буенча йөкләмәләрне тулысынча үтәү максатларында төзелгән заем шартнамәләре буенча заемнар алучы идарәче компанияләрдән акчаларны кайтаруны тәэмин итүдә Фондның бурычы;

Фонд тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр;

Килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән заем шартнамәләре буенча заемнар алучылар булган Фонд һәм идарәче компанияләр һәм (яисә) резидентларның бюджет акчаларын баш бүлүче һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан алар тарафыннан субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

идарәче компанияләргә заемнар бирү нәтиҗәләре, заемнар бирү нәтиҗәләренә ирешү турында идарәче компанияләр тарафыннан хисап бирү тәртибе, сроклары һәм рәвешләре;

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмауга китерә торган әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары бюджет акчаларын баш урнаштыручыга киметкән очракта яңа шартлар буенча килешүгә ирешмәгәндә Килешүнең яңа шартларын килештерү хакында яисә Килешүне өзү турында шартлар.

Кирәк булганда бюджет акчаларын баш бүлүче Фонд белән өстәмә килешү, шул исәптән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән типовой рәвешләр нигезендә Килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

11 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«D - идарәче компаниянең күчемсез милек объектларын арендалаудан асылда алынмаган керем күләме.»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчемсез мөлкәт объектларын арендалаудан сәнәгать (индустриаль) паркының, сәнәгать мәйданчыгының идарәче компаниясе резидентларының алынмаган керемен исәпләү 2020 елның апреленнән 2020 елның сентябренә кадәр ай саен гамәлгә ашырыла.»;

12 пунктта «Вәкаләтле орган» сүзләрен «Бюджет акчаларының төп бүлүчесе» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Фонд субсидия бирү елыннан соң килүче елның 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча бюджет акчаларын баш бүлүчегә субсидияләр бирү чыганагы булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән Килешүнең типовой формасында билгеләнгән рәвешләр буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап тапшыра.»;

14 пунктта:

беренче абзацта «вәкаләтле орган» сүзләрен «бюджет акчаларын баш бүлүче» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «вәкаләтле орган» сүзләрен «бюджет акчаларын баш бүлүче» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фонд тарафыннан Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап, өстәмә хисаплылык тапшырмау (Килешүдә каралган очракта);»;

җиденче абзацта «вәкаләтле орган» сүзләрен «бюджет акчаларын баш бүлүче» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

16 пунктта «вәкаләтле орган» сүзләрен «бюджет акчаларын баш бүлүче» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктта «Вәкаләтле орган» сүзләрен «Бюджет акчаларын баш бүлүче» сүзләренә алмаштырырга;

18 пунктта «вәкаләтле орган» сүзләрен «бюджет акчаларын баш бүлүче» сүзләренә алмаштырырга;

Әлеге Тәртипкә 3, 4 нче кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин